**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**БАКРЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАКЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 50-2-35, факс 50-2-35

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**19 .10. 2022** **№ 4**

**2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Татар Чагылдымы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Бакырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 10 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Чуаш Чагылдымы авылы, Чапаев урамы, 24 нче йорт адресы буенча урнашкан Чуваш Чагылдымы авылы клубында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Татар Чагылдымы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, бары тик көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, Менделеевск муниципаль районы мобилизацияләнгән, волонтерлар) һәм аларның гаилә әгъзалары, аерым алганда: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү

Татар Чагылдымы торак пунктында Газинур урамындагы 11нче йорттан 20нче йортка кадәр вак таш, ком сатып алу, нигез салу, ташу, җәю, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне түләү сметасы нигезендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау;

- Татар Чагылдымы торак пунктында (вак таш, ком сатып алу, нигез салу, ташу, җәю, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне түләү) ТКО җыю мәйданчыкларына килү юлларын урнаштыру?»

"КАРШЫ" "РИЗА"

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **И.М. Шәмсетдинов**